**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «06» маеннан № 138

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында» 2023 елның 7 июлендәге 156 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының «2024 елның 1 июленнән бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакын арттыру турында» 2024 елның 18 апрелендәге 03-12/2677 номерлы тәкъдим хаты нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 7 июлендәге 156 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе

җитәкчесенең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкче һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 31 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 29 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтеры) | | 29 500 |
| Бүлек башлыгы | 25 700 | 25 700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 23 300 | 23 300 |
| Бухгалтер | 22 000 | 22 000 |

Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып структурада кимендә 5 берәмлек штатлы 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов